РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2024 Буа шәһәре № 323 Бк/к

Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 сентябрендәге 396-п номерлы карары белән расланган «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

I

«Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр булдырганда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 12 сентябрендәге 780 номерлы карары нигезендә, гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү максатларында, Буа муниципаль районы

Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 25 сентябрендәге 396-п номерлы карары белән расланган «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» нигезләмәгә (29.12.2017 № 534-п, 18.11.2020 № 425/Бк/к, 28.11.2022 № 376/Бк/к, 29.12.2022 № 435/Бк/к, 13.06.2024 № 161/Бк/к карарлары ред.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары 1 нче таблицада китерелгән.

Таблица 1

| т/б | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Учреждение җитәкчесе | 27 560 |
| 2 | Оператив дежурный | 21 200 |

»

«

2. Әлеге карар Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Хәмидуллин